РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 46

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 29 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 июлендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2006 елның 3 февралендәге 37 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 04 июлендәге 306 номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 455 номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге 40 номерлы, 2017 елның 27 июлендәге 191 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 240 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 286 номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 330 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 365 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтада:

1.1.1. 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 елеш естәргә:

«4. Район Советы депутаты үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен, тулаем алганда аена алты эш көненнән дә артык булмаган чорда эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә»;

1.1.2. 19 статьяның 4 өлешендәге өченче абзацта «(оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар),» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

Заказ № 2625

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз кеченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов